РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Красноключинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423552, Нижнекамский район,
п. Красный Ключ, ул. Садовая, 2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Красный Ключ авыл җирлеге
Башкарма комитеты

423552, Түбән Кама районы,
Кызыл Чишмә поселогы, Садовая урамы, 2

тел./факс (8555) 45-70-80, электронный адрес: Krasnoklyuch.sp @tatar.ru, сайт: www. krasnoklyuchinskoe-sp.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.02.2020 ел № 3

Красный Ключ авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 31 гыйнварындагы 4 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 47 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына, җирле мәсьәләләрне хәл итү буенча, Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы һәм Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләрне раслау хакында» 2019 елның 11 апрелендәге 22 номерлы карарын игътибарга алып, карар бирәм:

1. Красный Ключ авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 31 гыйнварындагы 4 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» карары 2020 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Красный Ключ авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

И.К.Зәйнетдинов